Татарстан Республикасы
Әлмәт муниципаль районы
Рус Акташы авыл Советы

КАРАР

30 декабрь 2025 ел №11

Әлмәт муниципаль районы Рус Акташы авыл Советының «Әлмәт муниципаль районының Рус Акташы авыл җирлеге муниципаль хезмәткәрләренең, җирле үзидарәнең даими нигездә үз вәкаләтләрен гамәлгә ашыручы сайланулы вазыйфаи затларының хезмәте өчен түләү тәртибе һәм шартлары турында» 2018 елның «24» августындагы 107 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында

«Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында даими нигездә үз вәкаләтләрен гамәлгә ашыручы җирле үзидарә депутатларының, сайланулы вазыйфаи затларының, муниципаль берәмлекләрнең контроль-хисап органнарының рәисләренең, рәис урынбасарларының, аудиторларның, муниципаль хезмәткәрләрнең хезмәте өчен түләү чыгымнарын формалаштыру нормативлары турында» 2018 елның 28 мартындагы 182 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2025 елның 25 ноябрендәге 994 номерлы карары нигезендә

Рус Акташы авыл Советы КАРАР БИРӘ:

1. Әлмәт муниципаль районы Рус Акташы авыл Советының «Әлмәт муниципаль районы Рус Акташы авыл җирлеге муниципаль хезмәткәрләренең, җирле үзидарәнең даими нигездә үз вәкаләтләрен гамәлгә ашыручы сайланулы вазыйфаи затларының хезмәте өчен түләү тәртибе һәм шартлары турында» 2018 елның «24» августындагы 107номерлы карарына (Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Рус Акташы авыл Советының 2018 елның «05» декабрендәге 111 номерлы, 2020 елның 11 декабрендәге 10 номерлы, 2022 елның 27 октябрендәге 49 номерлы, 2022 елның 14 декабрендәге 54 номерлы, 2024 елның 26 июнендәге 89 номерлы, 2024 елның 12 декабрендәге 97 номерлы, 2025 елның 20 маендагы 110 номерлы карарлары белән кертелгән үзгәрешләр белән) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. карарга 1 нче кушымтадагы таблицаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Әлмәт муниципаль районы Рус Акташы авыл җирлеге муниципаль хезмәткәрләренең вазыйфаи окладлары күләмнәре

| Вазыйфаның исеме | Вазыйфаи оклад (хезмәткә түләүнең 11 төркеме) |
|---|---|
| Башкарма комитет җитәкчесе | 25 392 |
| Башкарма комитет җитәкчесе урынбасары | 24 885» |

1.4. карарга 2 нче кушымтада таблицаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Әлмәт муниципаль районы Рус Акташы авыл җирлегенең даими нигездә үз вәкаләтләрен гамәлгә ашыручы җирле үзидарәнең сайланулы вазыйфаи затларын ай саен акчалата бүләкләү күләмнәре

| Вазыйфаның исеме | Айлык акчалата бүләкләү күләме (хезмәткә түләүнең 11 төркеме) |
|---|---|
| Башлык | 25 401 |
| Башлык урынбасары | 18 254» |

2. Әлеге карарны Рус Акташ авылы, Төзүчеләр урамы, 14, Комсомол урамы, 12б, Акташ станциясе территориясендә урнашкан махсус стендларда халыкка игълан итәргә, шулай ук Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында (PRAVO.TATARSTAN.RU) һәм Әлмәт муниципаль районы сайты «Интернет» мәгълүмати-телекоммуникацион челтәрендә урнаштырырга.

3. Әлеге карар 2026 елның 1 гыйнвареннан үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

Рус Акташы авыл
җирлеге башлыгы

С.А.Белоногов